Государственное автономное профессиональное
образовательное учреждение
«Мамадышский политехнический колледж»

УТВЕРЖДАЮ
Зам. директора по ТО
_________В.В.Файзреева

«01» сентября 2023 г.

# ФОНД ОЦЕНОЧНЫХ СРЕДСТВ

для проведения текущего контроля и промежуточной аттестации
по дисциплине ОГСЭ.06 Татарский язык в профессиональной деятельности
для специальности
23.02.07 Техническое обслуживание и ремонт двигателей, систем и агрегатов

2023

Фонд оценочных средств разработан на основе рабочей программы учебной дисциплины ОГСЭ.06 Татарский язык в профессиональной деятельности общегуманитарного и социально-экономического цикла и в соответствии с вариативной составляющей части Федерального государственного образовательного стандарта среднего профессионального образования по специальности 23.02.07 Техническое обслуживание и ремонт двигателей, систем и агрегатов (Приказ Минобрнауки России от 9 декабря 2016 г. №1568, зарегистрировано в Минюсте РФ 26 декабря 2016 г. №44946)

Обсуждена и одобрена на заседании цикловой методической комиссии общегуманитарных и социально-экономических дисциплин

Разработала преподаватель:

________Р.Н.Кашапова

Протокол № 1
«28» 08 2023г.

ПЦК ________Л.В.Ямалиева_

Контрольно-оценочные материалы предназначены для оценки результатов освоения дисциплины «Татарский язык в профессиональной деятельности».

При организации текущего контроля используются следующие методы контроля: устный опрос, оценка за письменные работы(сочинение), защита индивидуальных учебных проектов, анализ ведения рабочей тетради. Форма промежуточной аттестации – дифференцированный зачёт

**Практические работы.**

**1.Переведите на татарский язык, составьте диалог, используя местоимения**

Автотранспорт – автотранспорт

Сломаться - ватылырга

Легковой автомобиль – җиңел автомобиль

Карбюратор – карбюратор

Индивидуальные транспортные оборудования – шәхси транспорт җиһазлары

Специальный - махсус

Заменить (заменять) – алмаштырырга

Стартер - стартер

Контроль-измерительные приборы – контроль-үлчәү приборлары

Механик – механик

Ремонтный пункт – ремонтлау пункты

Смотровой,-ая,-ое ...яма – карау ..ы, тикшерү ...ы ... чокыры

Повреждение – ватылу

Система регулирования тяговых двигателей – двигательләрне җайлау системасы

Покрышка автомобильная –автомобиль тышлыгы

Регулировать мотор – моторны көйләргә

Свеча – свеча

Колесо –тәгәрмәч

Уровень тормозной жидкости – тормоз сыек Задание:

2. **Место точек поставьте нужные буквы.**

а) К..ләм, мәк...лә, сәнг...ть, иг..тибар, г..рәп, дикък...ть, һәр...яклы, ел..язма, яшә...е, г...мер, шәфк...ть, сөйк...мле, я...гын, бор...нгы, шөг..ль, гаҗ...п, г...мьсез, мөст...кыйль, к...нәфер, кагыйд..., дәг...ва, дәв...м, мәгълүм...т, орч..к, йолд...з, Бөг...лмә, җәмг...ять, җәмәг..ть, фәк..ть, бөт...несе, һәл...к, вәг...дә, пәрәве.., к..рдәш, сәлам..т, мәг..риф, ядк..рь.

ә) Маш..на, ка..ш, реж..м, м..тор, юнә..ш, т..зек, к..пер, м..хан..к, л..тр, инж..н..р,кул..анма, каб...на, каб..ль, запа.., б..нз..н, яш..л, я..улык,п..чрак, г..р..ж,ху..а, авт..бус, аккумул..тор, аморт..затор, стаб..л..затор, стан..ия, св..тофор, сал..н, рул.., п..дал.., ном..р, һ..лак..т.

б) Мам..к, т..бә, в..ранда, әйб..р, бүр..нә, бл..к,асфал..т, мат..а, мәй...ан, авыр...ык, д..м, ш..реп, ...ава, ка..ка, га..ка, ка..ак, бал..ык, иш...к, так..а, т..мер, кала..., то..ак, җитешт..р..че, сын..у, кабел.., ташч..., к...рпеч, кат..ргы,ачк..ч, бу...у, акб..р, пыч..ы.

3. **Игра “Кайсысы артык?”**

а) укучы, студент, аспирант, төзүче;

ә)Идел, Нократ, Чулман, Казансу, Каспий;

б)Әлмәт, Казан, Азнакай, Бөгелмә, Балтач;

в)нарат, икмәк, чыршы, каен, имән;

г)Яңа ел, 8 нче Март, 9 нчы май, 17 нче март, 23 нче февраль;

д) өстәл, кашык

4. **Составьте предложения.**

Түлим, мин, штраф.Минем, килә, карыйсым, автобуслар, расписаниесен.

Кич, мин, белән, китәм.Калды, биш, поезд, минут, китәргә, безнең

Туры, киләчәк, ремонт, 100, түләргә, очен, ремонт, миңа.

Кирәк, бензин, тутырырга, бакка, сезгә.Бетә, асфальт, юл, кайда ?

Каптырып, куркынычсызлык, куегыз, каешларын, сез!

Ярамый, тәмәке, монда, тартырга, сезгә.

**5.Работа над текстом.**

Машина йөртүченең эш урынын оештыруга таләпләр.

Эш урынында кешегә хезмәт итү өчен кирәкле информация бирүче әйберләр, идарә һәм ярдәмче органнар урнаштырыла. Эш урыннары шәхси һәм күмәк булырга мөмкин. Алар утырып, басып һәм алмашып эшләү булдырылырга мөмкин.

Машина йөртүченең төп эш урыны булып кабинадагы утыргыч исәпләнә. Урындык, эшчегә, хезмәт шартына һәм уңайлыкка карап, гәүдәнең физиологик торышын тәэмин итәргә тиеш.

Утыргычның утыру өлеше, арка сөяге, кул аслыгы (култыкса), аяк куйгычы булырга тиеш. Утыргычның биеклеге көйләнә торган булырга тиеш.

Утыргыч идәнгә беркетү җайланмасы ярдәмендә урнаштырыла. Машиналарда куркынычсызлык каешлары белән тәэмин ителә.

Трактор яки автомобильдә кабина – тракторчы яки шоферның эш урыны ул, шуңа күрә анда уңайлы эш шартлары тудырылган булырга тиеш. Ул металлдан эретеп ябыштыру ысулы белән җыела. Аның идәне, ос һәм ян кормалары була. Ян кормаларда ышыклагыч тәрәзәләр һәм пыяла чистарткычлар, ишекләр, җилләтү һәм җылыту челтәрләре урнаштырыла. Кабинаның эче тавыш һәм җылы үткәрмәүчән материал белән каплана. Кабина двигатель өстендә (КамАЗ, ГАЗ-66) яки артында урнаштырылырга мөмкин.

**6.Работа над текстом.**

Машинагыз бармы?

Сезнең машинагыз бармы? Безнең юк иде. Машина алыр өчен, бик күп акча кирәк шул...

Әтинең дусты яңа машина сатып алган. Ә иске машинасын сатам, ди. Иске машина түгел әле ул. 3 кенә ел йөргән “Жигули».

Камил абый ул машинаны безгә тәкъдим итте. Ул кадәр акчабыз юк инде, билгеле. Ләкин Камил абый болай ди:

- 300 мең бар, дисез, банктан кредитка 100 мең алырсыз. 400 мең була. 50 меңне бурычка алып торырсыз. Була 450 мең.

Әтинең машина аласы килә. Бигрәк тә бакчага барып йөрү өчен кирәк, ди. Әни дә каршы түгел. Әти белән әни узара киңәштеләр дә машинаны алырга булдылар.Шулай итеп, без машиналы булдык.

1. Сезнең машинагыз бармы?

2. Ул машина өчен акчаны ничек җыйдыгыз?

3. Бу гаилә машинаны ничек алган?

4. Бу машина яңамы? Ул күпме тора?

5. Машина алгач, алар ничек яшәрләр?

6. Сезнең күршеләрегезнең, танышларыгызның ничә машинасы бар?

7. Ул машиналар искеме, яңамы

**7.Прочитайте. Переведите**

Һәркем аңлый. Һәр кеше аңлый. Һәр эшне әйбәт итеп эшләргә кирәк. Бөтен кеше кул чапты. Барлык студентлар катнашты.барчасына да бүлеп бирделәр. Һәркемне шаккатырды, һәммәсенә дә алма бирделәр. Барчасын залга җыйдылар. Кемдер сөйли башлады. Кемнеңдер җырлаганы ишетелде. Кемгәдер каршы чыкканнар. Кайберләре югалган. Кайберәүләргә авыр булган. Һичкемне белмим. Һичкемнән ишетмәдем. Һичнәрсә комачауламый. Беркем дә күренмәде. Бернинди тавыш юк. Ул бернәрсә дә белми иде. Бу эш сезнеке. Теге мунча безнеке.

**8.Переведите на татарский язык.**

Около пяти километров. Около метра. Около тридцати человек. Килограмм двадцать мясо. Дней двадцать. Центнера два-три. Семь-восемь ребят. Сколько стоит билет первого класс? Сколько часов стоит теплоход в этом порту? Масса багажа для бесплатного провоза не должна превышать 20 килограммов. Стоянка поезда № 8 будет сокращена до 10 минут из-за опоздания от расписания. Сколько стоит литр бензина? Отпустите, пожалуйста, мне десять литров бензина.

**9.Работа над текстом.“КамАЗ” – шәп машина!**

Мин күптәнге шофер, Ватаныбыз азатлыгы очен фронт юлларыннан да машина куган кеше...

Шушы һөнәрне яратканга, сугыштан кайткач колхазда машина йөртә башладым. Шуннан мине I автотранспорт берләшмәсенә күчерделәр. Монда “ЗИЛ-130” машинасына утырдым. Хәер, мин бер дә утырмаган һәм яратып эшләмәгән башка төр машина калдымы икән? Әмма аларның берсе дә “КамАЗ” белән ярыша алмый. Бик шәп машина ул – безнең “КамАЗ”: сигез тонна йөк күтәрсә дә ул тиз йөрешле, дизеле тавышсыз. Ял итим дисәң, мичен кабызып җибәрәсең дә, өйдәге кебек, җылыда йоклый аласың....

Мин тормышымнан да, эшемнән дә бик канәгать. Җитмәсә, инженер кызым Фирая да КамАЗда эшли. Һөнәремнән канәгать булганга, кызымның да хезмәте кергәнгә, “КамАЗ”ны йөртү миңа икеләтә рәхәт. (Ф.Галиевтан)

**10.Работа над текстом.**

**Тәмәке тартуның зарары.**

Иң киң таралган начар гадәтләрнең берсе – тәмәке тарту.Тәмәкедәге никотин үзәк нерв системасына тәэсир итә. Никотин – бик агулы матдә. Беренче тарта башланганда, күңел болгану, баш әйләнү, косу, йөрәк тибү, ярсыну һәм, шуннан соң, хәттә һуштан язу күренешләре була. Организм никотинга ияләшкәч, аның агулы тәэсире кими төшә, һәм кеше тәмәкенең рәхәт ярсытуын гына сизә. Ә бу – алдый торган тәэсир.Тәмәке төтенендә башка бик күп зарарлы матдәләр дә бар: синилҗ кислотасы, сөрем газы, аммиак, формадегит. Яман шеш булдыра торган бензопирен аеруча зарарлы. Тәмәке тартучы кешеләр арасында үпкә рагы 10 тапкыр күбрәк очрый, бугаз рагы – 6-10 тапкыр күбрәк була. Алар очен үпкә ялкынсынуы, туберкулез, бронхларда астма биш еш очрый торган күренеш.Тәмәке тартучыну, бигрәк тә тәмәке тарта торган укучыларның хезмәт һәм яу режимы бозыла. Укучының дәрес вакытында тартасы килеп, бөтен уе тәмәкегә күчә. Тәмәке тартучы укучылар тәнәфестә башкалар белән ял итмиләр, дәрес бетүгә, тәмәке тартырга урын эзләп йөгерләләр һәм бөтен тәнәфесне шунда үткәрәләр. Тәмәке тарту яхшы укуга кумачаулый, хәтәр начарлана.Тикшерүчеләр

әйтүенчә, тәмәке кеше гомерен 5-15 елга кадәр кыскарта. Бер сигарет гомерне 7 минутка киметә.

Кызганычка каршы, бу гадәт хатын-кызларда да очрый башлады. Бу аеруча зарарлы. Ни өчен? Хатын-кызлар – булачак аналар. Тәмәке тарткан хатын-кызлардан балалар зәгыйфь яисә гарип булып туулары мөмкин. Халыкара статистика мәгълүматларыннан күренгәчә, тартучы хатын-кызлардан тугаи яшь балаларның үлү очраклары 40 процентка артыграк.Юкка гына: "Тәмәке белән бергә тартучы да яна",- дип әйтмиләр.("Гаиләдә ир һәм кыз бала" китабыннан)

сөрем – копотьзәгыйфь –

слабый,хилый

гарип - инвалид, калека

яман шеш – раковая опухоль

бугаз - гортань, глотка

күңел болгану – тошнота

косу – рвота

һуштан язу – потерять сознание

ялкынсыну – воспаление

матдә – вещество

**11.Прочитайте и переведите.**

- Гафу итегез, сез миңа бензоколонкага юлны күрсәтмәссезме?
- Бензоколонкага кадәр җиде километр. Минем машина артыннан барыгыз.
- Рәхмәт. Бер литр бензин күпме торганын әйтмәссезме?
- 30 литр бензин алсагыз, ташлама ясыячаклар.
- Күбрәк бензин салсам, акчам азрак тотылыр. Рәхмәт, киттек.

**12.Работа над текстом.**

**Аракы кешене нишләтә?**

Шәраб, аракы, сыра эчү нәрсәгә китерә?

Суд язмаларыннан күренгәчә, җинаятьләрнең уннан тугызы исерек хәлдә эшләнә. Исерткеч эчемлекләр куллануның бер нәтиҗәсе әнә шуннан гыйбарәт.

Эчкече кешеләр каты авырулар белән авырыйлар һәм аларның күбәсе шушы авырулардан үлеп тә китә. Исерткеч эчемлекләр куллануның икенчесе нәтиҗәсе әнә шундый.

Шәраб кешеләрнең акылын һәм намусын тамалый; шәраб эчкән кеше тупасрак, аңгырарак, усалрак була бара.

Шәраб кешегә сәламәтлек тә, көч тә, җылы да, күңеллелек тә бирми, бары тик зарар гына китерә.

... Әгәр әле син беркайчан да эчмәгән, аракы белән агуланмаган яшь кеше икенсең, үзеңнең кадереңне бел! Шәраб күңелне күтәрә дигәнгә ышанма. Шәраб синең тормышыңны акылсыз һәм бозык күңел ачуга әйләндерә. Эчкәч, син аек хәлдә башыңа да китермәгән эшләрне эшләп ташлаячаксың. Шулай булгач, нигә дип үзеңне шундый коточкыч куркыныч астына куярга? (Л.Н.Толстойдан)

Шәраб – вино Сыра - пиво

Жинаять – преступление Гыйбарәт - заключается

Томамлый – заглушает Аек - трезвый

Коточкыч – страшный, чудовищный

1.Җөмләләрне дәвам итегез.

1)Җинаятьләрнең уннан тугызы ... . 2) Эчкече кешеләр каты авырулар ... . 3) Шәраб кешеләрнең акылын ... . 4) Шәраб кешегә сәламәтлек тә ... .5)Шәраб кешенең тормышын ... . 6) Хатың-кыз аракы эчсә, ... .7)Аракы эчкәч ... .

2.Схемалар буенча диалог төзегез.

а)Тәкъдим итү-риза булмау

аңлату-сорау бирү

исбатлау-риза булу

б)киңәш бирү-риза булмау,фикерне кире кагу

исбатлау-риза булу,килешү

Тема: Туган көндә исерткеч эчемлекләр алу,алмау.

3.Сез бу фикерләр белән килешәсезме?

-сырада алкоголь аз, аны эчсән , организмга зыян булмый;

-яхшы филҗтрлы сигаретта никотин аз, аны тарту зыянлы түгел ;

-яшь организмга һәр төрле исерткеч эчемлек тә зыянлы;

-тәмәке тарткан кеше янында тору сәләмәтлеккә зарарлы;

-тәмәке тартып, шәраб эчеп кафеда утыру, заманча яшәү.

**13.Работа над текстом.**

**“КАМАЗ-Мастер” юлга кузгалырга әзер**

Команда Чаллыдан 24 декабрьдә юлга кузгалачак. Ул быел «Дакар-2015»һәм «Африка Эко Рейс-2015» раллиенда катнаша.

Аргентинаның башкаласы Буэнос-Айреста легендар «Дакар» ралли-марафоны гыйнвар башында старт алачак. Анда 53 илдән 414 транспорт чарасы катнашачак.

«КАМАЗ-мастер» командасы катнаша торган «Africa Eco Race 2015» 28 декабрьдә башланып, 11 гыйнварга кадәр барачак. Бу ярышка команданың ике «сугышчан» автомобиле бара. Якташларыбызга уңышлар юлдаш булсын!

В Марокко завершился четвертый этап международного ралли-марафона Africa Eco Race-2015.

Вновь первым к финишу пришел российский экипаж под управлением пилота Антона Шибалова на дизельном «КАМАЗе», вторым стал чешский экипаж под управлением Томаша Томечека, третьим сегодня финишировал бельгийский экипаж под управлением Грегори Боувенса. Четвертым финишировал еще один российский экипаж под управлением пилота Сергея Куприянова на газовом «КАМАЗе».

Сегодня пройдет пятый этап ралли по маршруту As sakn - Dakhla. Его протяженность составит 752 км, из которых лиазон – 526 км, спецучасток – 226 км.

Завершает марокканскую часть ралли короткая дорога по каменистому ландшафту, которая заканчивается красочным спуском в огромное вади (пересохшее русло реки). На этом отрезке дорога станет очень извилистой, участникам предстоит преодолеть сложнейшее в навигации пересохшее русло реки Хамра. Чтобы добраться до бивуака, автомобили должны будут проехать вдоль отвесных скал с видом на Атлантический океан.

**14. Составьте диалог, используя нижеприведенные выражения:**

Можно вызвать автомеханика? – Автомеханик чакырып буламы?

Прошу вас накачать шины – Сездән шиннарны кабартуыгызны сорыйм

Спустило колесо - Тәгәрмәч җибәрде

Где можно отремонтировать автомобиль? – Автомобильне кайда ремонтлап була?

У меня спустила правая шина – Минем автомобильнең уң шинасы бушады.

Отрегулируйте, пожалуйста, углы установки передних колес – Рәхим итеп, алгы тәгәрмәчләрнең куелыш почмакларын көйләгезче.

Проверьте, пожалуйста, давление в шинах - Рәхим итеп, шиннардагы басымны тикшерегезче

Пожалуйста, замените колесо – Рәхим итеп, тәгәрмәчне алыштырыгызчы

Вам отрегулировать давление воздуха в шинах? - Сезгә шиннардагы һава басымын көйләргәме?

Сколько я вам должен за ремонт (услуги)? – Ремонт (хезмәтегез) очен мин сезгә күпме тиеш?

Вы можете устранить дефект прямо сейчас? – Сез кимчелекне хәзер үк төзәтә аласызмы?

У вас есть запасное колесо? – Сезнең запас тәгәрмәчегез бармы?

Сколько продлится ремонт? – Ремонт озакка сузылачакмы?

Ремонт будет стоить .... рублей – Ремонт очен ..... сум түләргә туры киләчәк

**15.Переведите на татарский язык.**

ГАЗ-А (рис.1). Первый легковой автомобиль, выпущенный в 1932 г. Горьковским автомобильным заводом.

Этот автомобиль не собирали из привезенных готовых частей, а весь изготовляли на заводе.

Мощность – 30 кВт, скорость – 90 км/ч.

М-1 (рис. 2). Этот автомобиль появился на улицах наших городов в 1936 г. Он был создан на Горьковском автомобильном заводе взамен устаревшей машины “ГАЗ-А”. Мощность – 37,3 кВт, скорость – 100 км/ч.

ЗИЛ-101 (рис. 3). Шестиместная легковая машина. Она появилась также в 1936 г. Сошла с конвейера Московского автомобильного завода, который теперь носит имя замечательного советского автомобилестроителя И.А. Лихачева. Мощность – 81 кВт, скорость – 120 км/ч.

“Победа” (рис 4). Год рождения машины – 1945, и названа она так в честь нашей победы над фашистской Германией. Еще шла война, а над проектом машины уже работали конструкторы Горьковского автозавода. Мощность – 39,0 кВт, скорость – 105 км/ч.

ЗИЛ-110 (рис 5). Автомобиль высшего класса, семиместный. Его создали на Московском автозаводе в 1946 г. Мощность – 105 кВт, скорость – 140 км/ч.

ЗИМ (рис. 6). Комфортабельный автомобиль среднего класса, шестиместный. Выпущен в 1949 г. Горьковским автозаводом. Мощность – 67 кВт, скорость 120 км/ч.

"Москвич" (рис 7). Чтобы выпустить эту машину, в Москве в 1947 г. Был специально построен завод малолитражных автомобилей. Ее знают и любят не только в нешей стране. Ее можно увидеть на многих дорогах мира. Первый образец мало похож на настоящий. Мощность – 55,2 кВт, скорость – 142 км/ч.

"Волга-24" (рис 8). Сейчас это самый распространенный легковой автомобиль в нашей стране. Все легковые такси- "Волга". Представленная на рисунке модель выпускается Горьковским автозаводом с 1970 г. Мощность – 69,9 кВт, скорость – 147 км/ч.

"Запорожец" (рис 9). Автомобиль, двигатель которого расположен не спереди, как обычно, а сзади и охлаждается не водой, а воздухом. Выпускает этот автомобиль Запорожский автомобильный завод "Коммунар". Мощность – 30,1 кВт, скорость – 118 км/ч.

"Чайка" (рис 10). Комфортабельная машина высшего класса. Выпускает ее Горьковский автозавод. Машина не только красивая, но и очень надежная и выносливая. Мощность – 161,8 кВт, скорость 175 км/ч.

ЗИЛ-4104 (рис 11). Легковой автомобиль, выпускаемый Московским заводом имени И.А. Лихачева. Приборы и управление у машины самые современные – полуавтоматические и автоматические. Мощность – 231,8 кВт, скорость – 190 км/ч.

ВАЗ-2109 (рис 12). Легковой автомобиль, выпускаемый Волжским автомобильным заводом имени 50-летия СССР. Мощность – 46,8 кВт, скорость – 148 км/ч.

**16.Прочитайте и переведите.**

Ял көннәрендә Лениногорск районы Бәкер авылы янында "Авторалли- 2015" бәйрәме узды.

Башка автоузышлардан ул аерылып торды: “Запорожең” машиналарында көч сынаштылар. Бәйгедә Арча, Нурлат, Сарабиккол, Шөгер, Бәкер кешеләре узышты. Ретро-машиналар яратучы ТР Дәүләт Советы Рәисе Фәрит Мөхәммәтшин барлык катнашучыларга кыйммәтле бүләкләр, медальләр тапшырды.

Ул Тула өлкәсендә «Жигули» автомобилендә полиция белән узыш оештыруда гаепләнә.

ЮХИДИ инспекторлары юлның бер ягыннан икенчесенә чайкалып килүче автомобильгә игътибар итәләр һәм аны туктатырга телиләр. Ләкин шофер туктарга уйламый да. Соңгылары корал кулланырга мәҗбүр була. Машинаның 3 тәгәрмәченә зыян китергәннән соң, ниһаять, ул туктый. Руль артында үзе белән шоферлык таныклыгы да булмаган 39 яшьлек казанлы булып чыга. Тиздән полицейскийлар машинаның номерлары да ялган булуын ачыклый. Теркәү билгеләре тәртип бозучының Тула өлкәсендә яшәүче этисенең «Запорожең» машинасыныкы булып чыга. Шулай ук әлеге адәмнең 2015 елның сентябренә кадәр машин йөртү хокукыннан мәхрүм ителгәнлеге дә ачыклана. Хәзерге вакытта тикшерү эшләре бара.

## 17.Чтение и перевод профессионально ориентированных текстов

### Яңа һөнәрләр.

Без укытучы, табиб, эшче, колхозчы, пешекче, официант, шофер, сатучы һәм башка һөнәрләр турында күп сөйлибез.

Хәзерге бик күп яңа һөнәрләр барлыкка килде. Брокер,эшмәкәр, эшкуар, шәхси сакчы, банкир, секретарь-референт, менеджер кебек һөнәрләр турында ишеткәнегез бардыр.

Заман үзгәрә, яңа тормыш яңа һөнәрләр таләп итә. Бу һөнәрләргә өйрәтә торган уку йортлары да ачыла. Аида уку, гадәттә, түләүле була.

Университетларда яңа факультетлар ачыла. Экономика факультетында заман таләпләренә җавап бирә торган икътисадчылар әзерлиләр. Халыкара мөнәсәбәтләр бүлегендә шул өлкәдә эшләргә тиеш булган белгечләр әзерләнә. Татарстан дистәләрчә илләр белән бәйләнештә яши. Шул

бәйләнешләр үссен өчен, бу эшне яхшы белгән, чит телләрдә яхшы сөйләшә торган белгечләр кирәк. Алар университетның шушы бүлегендә әзерләнә.

**Заманча һөнәрләр.**

Актуарий – ул кеше гомерен озак вакытка страховкалау өлкәсендә эшләүче белгеч. Түләү тарифларының фәнни нигезләнгән методларын гамәлгә кертү белән шөгыльләнә.

Титестер – чәйнең сыйфатын билгеләүче (дегустацияләүче) – сирәк очрый торган һөнәрләрнең берсе. Ул чәйнең сортын, сыйфатын, аның “тугаи җирен” билгели.

Рецепшонист – клиентларны каршылый, шәхси мәгълүматларын язып ала; килгән хатларны, телефоннан шылтыратуларны теркәп бара.

Офис-менеджер – офистагы эшнең тоткарлыксыз баруына җаваплы хезмәткәр. Ул сәркатибләр, машина йөртүчеләр, курьерларның эшенә күзәтчелек итә; офистагы оргтехниканың төзеклеген күзәтә һ.б.

**18.Отвечайте на вопросы и составить рассказ.**

1.Сез нинди яңа һөнәрләр беләсез?

2.Сезнең туганнарыгыз, танышларыгыз арасында нинди кызыклы һөнәр ияләре бар?

3.Сезгә нинди һөнәр күбрәк ошый?

**Әтием – үрнәк.**

Әтием шәһәрдә үскән. Ул профессиональ-техник көллиятендә укыган.

Әтием заводта токарь ярдәмчесе булган, аннары – токарь, аннан соң мастер булып эшләгән. Аның куллары алтын.

Әтием – хәзер цех начальнигы. Аны эшендә ихтирам итәләр, тәртипле, әдәбле, зыялы булган өчен яраталар.

Әтием безне дә эшкә өйрәтте. Мин пычак үткенли, көрәк саплый беләм, җир казый беләм, түтәл ясыйм....

Без әти белән балыкка йөрибез, урманга гөмбәгә барабыз. Әтием балык тоту серләрен белә, урманда гөмбәне тиз таба. Һәр гөмбәнең исемен белә, агачлар, үсемлекләр турында сөйләргә ярата.

Әтием, гомумән, күп белә. Казан урамнарында йөргәндә, ул безгә урам тарихын, ни өчен шулай аталганын, бу йортта нинди атаклы кешеләр яшәгәнен, кайда нинди вакыйгалар булганын кызыклы итеп сөйли.

Әтием белән әнием театрга, концертларга йөрергә яраталар.

Аларның дуслары күп. Безгә кунаклар еш килә.

Безнең әти матур итеп яши белә. Аның кәефе күтәренке, кешеләр белән һәрвакыт ягымлы итеп сөйләшә. Әтине күршеләр дә ярата.

*Слова и выражения:*

үткенли беләм – умею точить

көрәк саплый беләм – умею насаживать лопату на черенок

җир казый беләм – умею копать землю

сер – тайна

вакыйга – событие

күтәренке – приподнятое

ягымлы – ласково

**?**1. Малайның әтисе кайда үскән? Кайда укыган?

1. Малайның әтисе кем булып эшләгән?
2. Ул хәзер кайда эшли? Кем булып эшли?
3. Эшчеләрнең аңа мөнәсәбәте ничек?
4. Малайның әтисе балаларын нәрсәләргә эшләргә өйрәткән?
5. Малай әтисе белән кая барырга ярата? Ни өчен?
6. Әтисе кызыклы шәхесме?
7. Малайның әти-әнисе нинди кешеләр?
8. Кешеләр аның әтисен ни өчен яраталар?

**19.Бәхетсезлеккә очраган кешегә табиб килгәнче беренче ярдәм күрсәтү.**

Теләсә нинди шартларда: өйдә, урамда, ял вакытында кешенең кинәт каты авырып китүе яки бәхетсезлеккә очравы (имгәнүе, агулануы, пешүе һ.б.)

мөмкин. Мондый очракларда ашыгыч медиңина ярдәме күрсәтү таләп ителә. Авыруның яки бәлагә юлыккан кешенең язмышы табиб килгәнче ярдәм күрсәтүгә бәйле, шуңа күрә авыру янында булган һәркем ярдәм күрсәтә белергә тиеш.

Егылу, бәрелү-сугылу нәтиҗәсендә тәннең йомшак өске өлешләре имгәнү аеруча еш очрый. Бу вакытта тән авырта, бераз шешә, кан сава (күгәрә).

**Беренче ярдәм.** Бәрелгән урынга, боз яки кар салып, резин куык яисә, салкын суда чылатып, салфетка куялар. 15-20 минуттан соң ул урынны тыгызлап бәйлиләр, өстенә бозлы куык куялар.

*Баш бәрелгәндә* баш әйләнә, колак шаулый, күңел болгана, костыра; баш мне селкенгән булса, кеше аңын югалтырга мөмкин. Бәлагә юлыккан кешене башына салкын әйбер куеп яткырырга, якасын чишәргә кирәк. Косканда, башын бер якка боралар һәм бармакка бинт урап, авызын чистарталар.

*Күкрәк читлеге бәрелгәндә* сулаганда авырта, тын бетә, кеше күгәренә, йөрәк тибеше ешая. Бу очракта авыруның гомерен ашыгыч операңия ясап кына саклап була.

*Буыннар таюны* каты авыртудан, хәрәкәтләндереп булмаудан беләләр. Зарарланган аяк-кул торышы табигый булмый, формасы да үзгәрергә мөмкин.

**Беренче ярдәм.** Бинт яки яулык белән җайлап бәйләргә яки шин салырга һәм бәлагә юлыккан кешене шундый ук травматология пунктына озатырга кирәк.

*Сөяк сынганда* бик нык авырта, аяк-кул нормаль хәрәкәтләнми, кәкрәеп һәм кыскарып кала, сак кына капшап караганда, сынган урын тагын да ныграк авырта. Тышкы сыну вакытында яра була, аннан сынган сөякләр чыгып торырга мөмкин.

**Беренче ярдәм.** Авыртуны киметергә. Сынган сөякләрнең урыныннан күчүенә юл куймаска. Моның өчен иң элек сынган аяк-кулны бөтенләй хәрәкәтләнмәслек итеп бәйләргә һәм аннан соң бәлагә юлыккан кешене дәвалау учреждениесенә илтергә кирәк. Зарарланган кулны – гәүдәгә, сынган

аякны сәламәт аякка тыгыз итеп бәйләп куялар. Кул астындагы теләсә нинди материалдан (такта, таяк, зонт һ.б.) шин салу аеруча яхшы нәтиҗә бирә. Шинның озынлыгы, зарарланган сөякне уртада калдырып, ике буынга җитәрлек булырга тиеш. Зур сөякләр (бот, кулбаш) сынганда, аяк-кулның өч буынына да җитәрлек озын шин табарга кирәк. Бот сөяге сынганда, бу шин култык астыннан табанга кадәр җитәргә, хәтта аннан бераз озанрак та булырга тиеш.

Икенчедән, кыскарак шинны бот башыннан аякның эчке ягына куялар. Башта шинны бинт яки сөлге белән урыйлар. Шиннарны аяк-кулга бинт белән урап ныгыталар. Бот сөяге сынганда тышкы шинның өске өлешен гәүдәгә беркетеп бәйлиләр. Ачык сыну вакытында, югарыда әйтелгәнчә, яраны эшкәртеп бәйлиләр.

Табиб килгәнче вакытында һәм дөрес ярдәм күрсәтү организмда шок хәлен булдырмый кала. Шок булганда кеше бик нык хәлсезләнә,сүлпәнләнә, әйләнә-тирәгә битараф була, агарына-күгәренә, тәне суына, пульсы ешая, йөрәк тибеше начарлана, кан басымы төшә. Андый хәлдәге кешегә ашыгыч медицина ярдәме күрсәтергә кирәк.

*Слова и выражения:*

җәрәхәт – травма

таю, каймыгу, буын чыгу – вывих

сыну – перелом

өзелү – разрыв

сузылу, тартылу – растяжение

бәрелү – ушиб

егылырга – падать, упасть

аң югалту – потеря сознания

аңга килү – приходить в сознание

сугарга – ударить, ударять

имгәнү – повреждение

мин кулымны каймыктырдым – я вывихнул руку

беркетеп бәйләп кую – фиксирующая повязка

бинт белән тыгыз итеп бәйләү – тугая повязка

суыту – охлаждение

катлаулы – сложный

күзгә ике булып күренү – двоение в глазах

**Промежуточная аттестация: дифференцированный зачёт**

**Каждый студент защищает презентацию, используя изученные темы «Моя будущая профессия»**

## Кулланылган әдәбият

1. Татар теле: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 10 нчы с-ф. - Р.К. Сәгъдиева. - Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2017. - 247 б.

2. Татар теле: рус телендә урта гомуми белем бирү оешмалары өчен уку әсбабы (татар телен туган тел буларак өйрәнүче укучылар өчен) 11 нчы с-ф. - Р.К. Сәгъдиева. - Казан: “Мәгариф – Вакыт” нәшр., 2017. - 286 б.

3. Татарча сөйләшәбез СТО, СТМ группа студентларын татар теленә өйрәтү буенча методик ярдәмлек.. Захарова З.Ө. - Әлмәт “ГАПОУ Әлмәт һөнәр көллияте” 2015.- 100 б.

**Фәнне үзләштерүнең нәтиҗәсен тикшерү һәм бәяләү**

| **Укыту нәтиҗәсе**<br>**( белергә, эшләргә тиеш)** | **Уку нәтиҗәләрен тикшерү һәм бәяләү формалары һәм алымнары** |
|---|---|
| **Укучыларның үзләштерергә тиешле белем – күнекмәләре:**<br>1.Татар теленең сүзлек составын белү. Лексикография буенча тулы мәгълүмат бирә белү.<br>2.Һөнәр өлкәсенә караган сүзләрнең төзелешен, ясалышын, кушымчалар турындагы белемнәрне ныгыту.<br>3. Сүз төркемнәре. Синтаксис буенча тулы мәгълүмат алу.<br>4. Язу тарихын тирән белү.<br>**Сөйләм эшчәнлегенә таләпләр:**<br>1. Төрле сүзлекләрдән файдалану күнекмәләрен булдыру.<br>2. Сөйләмдә сүз төркемнәреннән дөрес һәм урынлы файдалану, төгәл итеп анализлау<br>3. Сүз ясалышын, төзелешен, сүзтезмәләрне тикшерү үрнәкләрен камил белү.<br>4. Орфографик прициплар һәм аларның нормаларын белү.<br>7. Стилистика һәм сөйләм культурасы нормаларын төгәл белү.<br>8. Пунктуация кагыйдәләреннән дөрес файдалану.<br>9. Сөйләм эшчәнлеге буенча тулы мәгълүматлы булу. | сорауларга җавап бирү; күнегүләр эшләү; конспектлар төзү,тәрҗемә эше,презентация ясву. |